Татарстан Республикасы  Мамадыш муниципаль  районы муниципаль
бюджет мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү учреждениесе
“Көек Ерыкса балалар бакчасы”

# Проект.

# Сугыш чорында әби-бабайларыбызны ачлыктан алып калган үсемлекләр



Тәрбияче: Шәйхетдинова М.В

I квалификацион категорияле тәрбияче.

Мамадыш, 2021

**Эчтәлек**

Проект. Үсемлекләрне өйрәнәбез. Сугыш чорында ачлыктан алып калган үсемлекләр.....3
Кереш.....7
Авылым тарихы.....9
Безнең тирә-ягыбызда үсә торган дару үләннәре.....11
Әбием киңәшләре.....11
Хәкимҗан Халиков шигырьләре.....12
Йомгаклау.....12
Кушымта 1- Убыриянең сихри аланында.....14
Кушымта 2-Витаминнар.....21
Кушымта 3-Безне үлемнән алып калган үсемлекләр.(Тыл ветераннары белән очрашу).....24
Кулланылган әдәбият.....26

**Бурыч:** Бөек Ватан сугышы елларында ачлыктан алып калган үсемлекләр белән танышу.

**Максат**: Бөек Ватан сугышы турында мәгълүмат бирү. Балаларга патриотик тәрбия бирү; халкыбызның Бөек Ватан сугышы елларындагы батырлыклары белән горурлану хисе тәрбияләү, ветераннарга хөрмәт тәрбияләү.Сугыш темасына әдәби әсәрләр уку, музыка тыңлау. Ашарга яраклы үсемлекләр таныргa,аталышын белергә; аларны кулланырга өйрәтү һәм дөрес җыю турында белемнәрне тулыландыру. Шигырьләр ятлау, әңгәмәләр үткәрү аша балаларның сүз байлыкларын баету, хәтерләрен үстерү.

**Проект тибы:** төркем белән, әти-әниләр белән берлектә.

**Белем бирү өлкәләре:** танып белү, сөйләм үсеше, нәфис - нәфасәти үсеш, социаль - коммуникатив үсеш, физик үсеш.

**Проектның дәвамлылыгы:** июнь-май

**Фараз*:*** Әгәр дә тәрбия эшендә балаларга , туган илгә, халкыбызга ,аларның үткәненә карата мәхәббәт тәрбияләүдә төрле чаралар үткәрелә икән, димәк, бу аларның патриотик хисләрен формалаштыруда зур роль уйнаячак.

**Эчтәлекнең төре:** Бала, тирә-як мохит, туган якның тарихи һәм сәнгать истәлекләре.

**Проектның этаплары.**

1.Алдан башкарылган эш:Перспектив эш планы төзү, фотога төшү, проектны иллюстратив материаллар, гербарийлар белән баету,ата-аналар өчен анкеталар үткәрү; методик китаплар һәм матур әдәбият әсәрләре сайлау, проект турында әңгәмә оештыру.

Балалар бакчасын мәктәп, китапханә,мәдәният йорты,медпункт , мәчет белән тыгыз элемтәдә тотып, бергә хезмәттәшлек итү.

2.Төп өлеш. Бөек Ватан сугышы турында таныштыру, сугышта катнашкан авылдашларыбызның һәйкәлендә булу һәм чәчәкләр салу, истәлекле урыннар турында шөгыльләр, тыл ветераннары белән очрашулар үткәрү, экскурсияләр оештыру.

Тарих укытучысы Руслан Миннефаилевич тарафыннан “Сугыш чорында ачлыктан алып калган үсемлекләр” турындагы чыгышын тыңлау.

Туган якның байлыгын, табигать матурлыгын күзәтү,ашарга яраклы үсемлекләр белән танышу максаты белән авылның тирә-як басу-кырларына, чишмә - су буйларына , тауга сәяхәткә чыгу.
Әти-әниләр ярдәме белән “Убыриянең сихри аланында” бәйрәм иртәсе үткәрү.
Консультацияләр оештыру,ата-аналар белән әңгәмәләр кору.
“Дару үләннәрен һәм ашарга яраклы кыргый үсемлекләрне беләбезме?” анкета уздыру.Сюжетлы-рольле уеннар уйнау “Гаилә”, “Мәктәп”, “Балалар бакчасы”, “Ватанны саклаучылар”.
Авылда үткәрелгән конкурсларда, концертларда, милли бәйрәмнәрдә катнашу; мәдәният йортында балалар белән чыгыш ясау.
Авылыбыздан сугыш чоры балалары Гараев Фазыл, Сахабиев Ханнан абыйлар, Шәйхетдинова Әминә, Миннахметова Гөлсем, Вәлишина Венера апалар белән очрашу, әңгәмәләр үткәрү. Әти-әниләр ярдәме белән, сугыш чоры балалары-әби-бабайлар турында мәгълүмат туплау.
**Проектның актуальлеге.** Ни өчен мин бу теманы сайладым соң? Бүгенге көндә, фән һәм техника гөрләп чәчәк аткан заманда ни өчен кешеләр иртә китә? Ә бит безнең әби –бабайларыбыз нинди авыр чорлар үтеп,ачлыкны күреп “черек бәрәңге “ашап та ,бүгенгесе кондә матур гына яшәп яталар.Димәк алар тукланган ризык файдалы ,витаминнарга бай булган .Бүгенгесе көндә ул үсемлекләр үсәме, кулланышта бармы, алар үз әһәмиятләрен югалтмадылармы? Ашарга яраклы үсемлекләрне таный, дөрес җыя белү, халык медицинасының тормышта кулланылуын белү кирәкме?
Табигый үсемлекләр авыруларны сихәтләндерә, хезмәт кешесенә көч-куәт бирә, сәламәтлекне ныгыта.Ә бит авыр сугыш елларында ,шул үләннәр ярдәме белән исән калганнар. Алар чын мәгънәсендә ачлыктан алып калганнар.
Быел халкыбыз 9 нчы майда 75 нче тапкыр Җиңү көнен бәйрәм итә. Еллар аша күчә-күчә бу бәйрәмнең дә төп мәгънәсе югала бара, минемчә. Бу бит хәтер көне, сугышта һәлак булганнарны искә алу көне. Ә хәзер ул күңел ачу бәйрәменә әйләнә бара. Чөнки бу сугыш афәтен үз җилкәсендә татыган солдат һәм тыл хезмәткәрләренең сафлары кимегәннән кими бара.Шуңа күрә балаларга Җиңү көненең асылын аңлату бик мөһим.

<u>**Проектның планы:**</u>

| **Белем бирү өлкәләре** | **Эшләү алымы һәм формасы** |
|---|---|
| ***Танып белү үсеше*** | “Авылның истәлекле урыннары”на экскурсия, авылыбызның сугышта катнашканнар һәйкәлендә булу,җыештыру. Китпаханә, фельдшер акушерлык пунктына,мәктәпкә сәяхәтләр оештыру. Дару үләннәре җыю.Борынгы газеталар карау.Элеккеге фотолар аша хәзерге авылны чагыштыру.“Туган якны өйрәнәбез” альбомы белән танышу. Авылдагы климат шартлары турында әңгәмә.Төрле үсемлекләр дөньясы, яшәү тирәлеге турында альбомнар булдыру.Экологик әкиятләр сәхнәләштерү.Табигатьне саклау буенча төрле чаралар уздыру. Агачлар утырту, бакчаны чиста тоту, бакча тирәли субботниклар ясауда өлкәннәргә булышу. |
| ***Сөйләм үстерү*** | “Туган авылым –Көек Ерыкса”,”Авылым урамы” шөгыльләре.,”Шушы яктан,шушы туфрактан без”, әти-әниләр, тәрбиячеләр өчен күңел ачу иртәләре.“Безнең якта үсүче дару үләннәре.”.“Витаминнар”-эшчәнлек ;“Үсемлекләр дөньясы, турында табышмаклар кичәсе үткәрү.“Шалкан” әкиятен сәхнәләштерү.”. |
| ***Физик үсеш*** | **Сюжетлы-рольле уеннар:**<br>Дарухanә..,Ватанны саклаучылар.Балалар бакчасы.Гаилә. Шифахәнәдә.<br>**Дидактик уеннар:**<br>Урман дусларын ярата.Безнең якта үсүче без ашардай үсемлекләр.. Бу кайчан була? Сәяхәткәниләр кирәк? Рәссам нәрсәне бутаган? |
| ***Нәфис-нәфасәти үсеш*** | **Рәсем**.<br>Минем авыл.Мин яшәгән йорт. Көзге урман.Әкияти өйләр.<br>Мин балалар бакчасыннан әти-әнием белән кайтам. |

| | |
|---|---|
| | **Кисеп ябыштыру**<br>Яфраклардан бизәкләр.Урман аланында гөмбәләр үсә.<br>**Әвәләү**<br>Табигый материаллардан эшләнмәләр. Балалар эшләреннән күргәзмәләр.<br>**Музыка**<br>“Күрәсем килә”; “Әбием”,”Шәп бабай”<br>“Дружат дети всей земли” (сл.В.Викторова, муз.Д.Львова-Компанейца)<br>«Улыбка»( муз В.Шаинского, сл. Пляцкова)<br>“Мин яратам сине,Татарстан! (Р. Рәкыйпов сүзл, Р.Андреев муз)<br>**Җырлы-биюле уеннар**<br>Кәрия-Зәкәрия.Чума үрдәк,чума каз.<br>Челтәр элдем читәнгә.Миңлебай.Күрсәт әле,Габдулла. |
| ***Социаль-коммуникатив үсеш*** | Авылның мәртәбәле, мактаулы шәхесләре,тыл ветераннары ,өлкәннәр белән очрашу.Авылдашларыбыз сугыш чоры балалары беләночрашулар үткәрү Авыл буенча сәяхәт. Китапханәгә бару.<br>Төркемдә “Туган як” почмагы, “Әбием сандыгы” милли музей булдыру. |

## Көтелгән нәтиҗәләр:

1.Балаларның уеннар,очрашулар,күзәтүләр аша сугыш елларындагы авылдашларыбыз тарихы, аларның ашаган ризыклары турындагы белемнәрен формалаштыру.

2.Балаларның эзләнү-танып белү эшчәнлеге киңәю, үзләре өчен файдалы белемнәр туплауларына ирешү.

3. Авылның өлкән кешеләренә хөрмәт уяту ,патриотик хисләр формалаштыру.

4. Халыкның гореф-гадәтләрен саклап калуга ирешү.

5. Безнең проект аша әби-бабайларыбыз һәм ашарга яраклы үләннәр турында күбрәк белерләр дип көтәбез.

**Кереш:**

Сугыш... Меңәрләгән шәһәрләрне җимергән, җир йөзендә гөрләп торган авылларны юкка чыгарган, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып, көлгә әйләнгән. Сугыш чоры балалары ачлыкны да, ялангачлыкны да кичергәннәр..Бу дәһшәтле елларда туган авылыбызниләр кичерде икән? Менә шушы сорау безне һәрвакыт уйланырга мәҗбүр итә. Сугыш еллары елдан- ел артта кала,әбиләребез-бабаларыбыз сафлары елдан ел сирәгәя .Яшь буын бу хакта бик аз белә. Шуңа күрә, исәннәрдән, якташларыбызның Бөек Ватан сугышында күргәннәрен, белгәннәрен, кичергәннәрен эби –бабайлар сөйләвеннән генә белә алабыз..

Кызганычка каршы, безнең авылда бер генә сугыш ветераны да юк.Тыл ветераннары соңгы биш ел эчендә 36 кешедән 18 тыл ветераны гына авылыбызда гомер кичерә. Алар турында мәгълүмат җитәрлек тупланган. Ә сугыш чорында балалар ничек яшәгән? Әлеге буын кешеләренең тормышы турында без бик аз беләбез. Ә бит алар, сугыш чоры балалары, төп югалтуларга дучар булучылар. Сугыш аларга бик иртә тормыш йөген тарттыра, бик иртә олыгайта. Аларга сугышка китүче әтиләрен, абыйларыналыштырырга туры килә. Аларның киләчәге, тынычлыгы өчен әтиләре,абыйлары сугышка китә, күбесе кире әйләнеп тә кайтмый. Әти сүзен әйтергә тилмергән, әти назын тоярга сусаган күпме балалар, яшь буын... Барлык авыр эшне хатын-кызлар һәм балалар башкарган. Тылда калган халык ач. Иртә яздан кычытканның,сәрдә,чөгендер,балтырган,юа, какы, алабутаның яшь яфракларын ашаганнар.Кардан ачылган җирдән черек бәрәңге җыеп, аның крахмалын ипи, күмәч пешергәндә кушканнар..

Сугыш чоры баласы без,
Без күргәнне эт күрмәс.
Ачлык сүзенең мәгънәсен
Үзе күрмәгән белмәс.
Ачлыктан үлмәскә теләп
Ни генә ашамадык.
Җир өстендә алабута
Кычытканда калмады.

Черек бәрәңге эзләргә
Киттек язын кырларга.
Чабатабыз өзелеп калды
Язгы,бозлы суларда.
Бәхет иде әгәр тапсак
Дүрт-биш черек бәрәңге
Яшел үлән ашар өчен
Көтә идек җәйләрне.

Үсемлекләрдән башка бу дөньяны күз алдына да китереп булмый.Алар бөтен тереклек ияләренә суларга гына түгел, дәваланырга да булышалар. Кешеләр борынгы заманнарда ук хайваннарның кайбер үсемлекләргә игътибар иткәннәрен күргәннәр . Шуннан бу үсемлекләрне өйрәнә башлаганнар,аларның файдалы якларын ачканнар, китап итеп теркәгәннәр. Андый кешеләрне “үлән җыючылар” дип йөрткәннәр. Яшел тылсымчылар борынгы заманнан бирле кешеләрне дәвалаганнар,аларга көч биргәннәр.Медицинага нигез салучы Гиппократ 236 үсемлекне кулланган. Ә безгә исеме әкиятләрдән билгеле булган күренекле таҗик табибы Әбугалисина 900 гә якын үсемлекнең файдасы турында яза. Ә инде Россиядә 1581 елда беренче даруханә ачыла,




**Авылыбыз тарихы.**

1941 елда Бөек Ватан сугышы башлангач ике авылдан 345 ир-егет сугышка китәләр. Бөтен эш хатын-кызлар, картлар һәм балалар җилкәсенә кала.Сугышта 238 авылдан Ватан өчен тормышларын бирәләр.Исхаков һәм Бакыев Салихлар, Салахиев Фатих, Шәйдуллин Әбелхәсән, Газизуллин Газизҗан,Сагыйров Кадыйр һ.б. бик күп авылдашларыбыз орденнар һәм күп авылдашларыбыз орденнар һәм күп авылдашларыбыз орденнар һәм медальләр белән бүләкләнәләр. Җиңүнең 75 еллыгына Көек Ерыкса һәм яңа Комазан авылларында сугыш ветераннары калмады,ә тыл ветераннарының унҗидесе бүгенгесе көндә исән сау гомер

кичерәләр. Чагыштыру өчен сугышның 70 еллыгында 37 тыл хезмәткәре һәм бер сугыш ветераны –Динмухаметов Галиәхмәт абый исән булган.

## *Гараев Фазыл Харрас улы*



Минем бабам Гараев Фазыл Харрасович 1937 нче елның 4 февралендә дөньяга килә. Бабам сүзеләренә караганда,ул үз этисен тездән саз жырып ,1942 нче елның яз көнендә сугышка озаткан. Аңа бу вакытта ни бары 4 яшь кенә булган.Шуннан бирле,ул үз этисен күрмәгән. Алар этисез калганда гаиләдә 4 бала : 3 кыз һәм 1 малай булган. Бабам үз этисе урынына калып ел дәвамында суык димәгән, эссе дип тормаган, " ухалла" арбасын тартып болыннан утын һәм печән ташып йөргән. Кибеттән аларга акча булмаганлыктан яз һәм көз черек бәрәңге ташып ашаганнар. Мәктәптә дә 3 класс кына укып кала алган, чөнки энисенең аны укытырга мөмкинлеге булмаган. Бик яшли көенчә бабам колхозга эшкә керә.Олылар белән эшләп йөреп плотникка эшенә өйрәнә һәм гомер буе балта остасы булып эшли. Хәзерге вакытта лаеклы ялда, 3 бала үстереп 5 оныгы булуына сөенеп бетә алмый һаман да. ***(Гараева Инзилә)***

## **Шәйхетдинова Әминэ Мирзахановна**

Мин Шәйхетдинова Әминэ Мирзахановна 1937 елның 20 августында туганмын. Мина 3 яшж вакытта. 22 июнж 1941 елда сугыш башлана. Безнең этиебез сугышка беренче булып китә. Без өч бала: абый 7 яшь , мина 3 яшь, сеңлемә 1 яшь тә тулмаган була. Сугыш: авыл-районнарга,барлык өйләргә авыр тормыш башлана.Ачлык, хәерчелек,өс-баш юк барлык әйбер сотдатларга, сугышка китә. Кием-салым,ризык сугышка. Ягарга утын юк. Тылдагы кешеләр,әниләр урман кисәргә китәләр, ялга гына кайталар. Ул вакытта завод-фабрикалар утын ягышлы булган.Өйдәге өч балалар салам ягып ңылына,безнең урамда безне барлаучы Әһли бабай бар иде. Мәктәпләр суык, ягарга утын юк,балалар мәктәпкә бара алмый,өс-баш юк.Безнеө ашаган ризыкларыбыз: кычыткан,юа, камыш тамыры, алабута, нәрсә туры килә шуны ашадык. Кич ңитсә тәрәзәләрне каплаталар иде, бомба самолеты очса, авыл икәнен белмәсен. Без, этәйне кайтыр дип көткәндә,үлгән хәбәре килде.Тверь өлкәсе, Ржевск районы, Дешевлево авылында жирләнгән. 1942 ел 28 январь. Мин укырга сугыш туктагач, Комазан мәктәбенә бардым, ул 4 еллык иде,безгә этәйләр сугышта үлгәннәргә киемнәр бирделәр.Мин 4 классны "5" кә бетердем дә, 5 нче класска Көеккә бардым,ул вакытта да, китап-дәфтәрләр бик юк,шулайда сугыш беткәч сөендек,барыбер этиләре кайткан балаларга карап,без елап, йөрәк ярaлы,авырлык белән яшәдек. Ходай бүтән сугышны күрсәтмәсен!! (Әминә әбиегез)

## **Сахабиев Ханнан Раеф улы**

Минем бабам, Ханнан, 1941нче елның 3нче ноябрендә туган, этисен ул бөтенләй күрми, чөнки этисе ул туганчы сугышка киткән була. Әни безгә ачтан үлмәсеннәр



дип, юа, кычыткан, черек бәрәңге әзерләп ашаткан, дип искә ала  бабам. Ә сугыш беткәч,1947нче елны укырга кергән ул. Кечкенә булгач,  бабам, сугыш турында өлкәннәр сөйләгәннән генә белә. Сугыш беткәнгә дә 75 ел узып бара, әмма аның дәһшәте – көл булган шәһәр авыллар өстендә, яу кырыннан кайтмый калган ир- егетләр , эти- бабалар каберлегендә. Аның сары сагышы безнең- этисезләр йөзендә. Без сугыш дигән ачы хәсрәтнең фаҗигасен туганнан ук тоеп, үз күзләребез белән күреп, ачлык- ялангачлыкның ни икәнен татып үстек. Без, шул  утлы елларда туган балалар. Шуңа да бабам, сугыш елы авырлыкларын оныкларга күрергә язмасын, ил көннәребез тыныч булсын, оныклар белән бәхетле картлыкта яшәсәк иде,дип әбием белән бергәләп безне сөендереп, дога кылалар. ***(Сахабиева Гүзәл)***

**Вәлишина Венера Габделбәр кызы**

Мин 1 класска 1941 елда кердем. Сугыш башланган ел иде. Башлангыч класста уку чорын беткәнче сугыш елларына туры килде. 4 класста чакта Җиңү бәйрәмен зур тантана белән билгеләп үттек һәм бәйрәм иттек.

Әйе, авыр еллар иде бу.  Язарга ручка, карандашлар, дәфтәрләр булмады, дәреслекләр дә җитмәде. Каз канаты каурыеннан перо, корымнан кара ясап, иске газета, иске китап битләренә яза идек. Класста бер – ике генә китап белән дә укырга, язарга өйрәндек, тырышып укыдык.



Мәктәптән кайткач, көз көне башак җыя идек. Үзебез шунда бодай, борчаклар куырып ашый идек. Ашау – эчү дә иркен булмады. Җәй көне без әнисләр, кузгалаклар җыярга бара идек. Аны алып кайткач, капка төбендә, я ишек алдында утырып ашый идек. Җиләк җыярга бара идек. Хәзерге шикелле туеп ашамадык ул чакта. Мәктәпкә җылы киемнәр җыюда булыша идек. Аларны фронтка җибәрәләр иде. Авыр еллар булса да, безне укытучылар укырга да, хезмәткә дә өйрәттеләр. Әниләребез белән бергә без дә көчтән килгәнчә Бөек Җиңүгә ярдәм иттек. Һәм үзебезнең өлешне керттек. (Зиннурова  Әминә)

**Безнең тирә-ягыбызда үсә торган дару үләннәре**

Сары мәтрүшкә– хайваннарны үтерми.ә сызлану барлыкка китерә. Зарарлы микробларны бетерә.Элекке заманнарда бу үләнне 99 чиргә дәва дип йөрткәннәр.

Көтүче сумкасының җимеше көтүчеләр асып йөри торган сумкага охшаган. Исеме шуннан килеп чыккан.Канны туктата, яраны төзәтә.

Сукыр кычыткан тынычландыргыч чара буларак кулланыла.Йөрәк эшчәнлеген яхшырта.

Зәңгәр мәтрүшкә ютәлне баса. Сулыш юллары ялкынсынганда, баш авыртканда эчәләр.

Гөлбадран суалчаннарны куа. Ашказаны-эчәк авыруларын дәвалый.

Каен җиләкләренең яфракларын һәм җиләген файдаланалар.Сусауны баса, ашкайнатуны яхшырта. Җиләк һәм яфрак төнәтмәләрен салкын тигәндә эчәләр.каен җиләкләре яфраклары төнәтмәсе кан басымын төшерә,кан тамырларын киңәйтә,хәл кертә.

Күкчәчәк чәен йөрәк авыртканда, бөер авыртканда эчәләр. Аппетитны яхшырта, төнәтмәне сулыш органнары авыртканда, баш авыртканда, температураны төшерү өчен кулланалар.

Канлы үлән (чистотел) согы белән яраларны дәвалыйлар,сөялләрне бетерәләр. Канлы үләннән ясалган дарулар белән тире авыруларын дәвалыйлар.

Бака яфрагы кайнатмасы белән теш сызлаганда,теш уртлары ялкынсынганда авызны чайкыйлар. Пешекләнгән яфракларын үлекләгән урыннарга, яраланган урыннарга, сөялләргә ябалар.

Дару үләннәрен дөрес итеп әзерли дә белергә кирәк. Барлык дару үләннәрен дә чәчәк аткан чорда җыярлар. Җыйганнан соң караңгы,җиләс җирдә киптерергә. Кипкәннән соң бәйләп куярга яки савытларда сакларга кирәк.

## Әбием киңәшләре.

1.Ашказаны авыртканда 1әр кашык кычыткан,бака яфрагы,сары мәтрүшкә,ромашка чәчәген 1литр кайнар суда пешерергә һәм 2сәг.җылы урында төнәтергә.1әр стаканлап,көн буена литр ярым эчәргә.

2.Үлекле ярага күкчәчәк файдалы. Күкчәчәкне кайнап торган суга салып кайнатып алырга,марляны шунда чылатып ,яраны бәйләргә.

3.Тузганактан сыгып алынган су белән көн саен ышкысаң сөял бетә.4.Тән пешкәндә бака яфрагы орлыгының куе төнәтмәсен кулланырга.Ул болай ясала:1аш кашык орлыкны 0,5л кайнар суга салыгыз һәм яхшылап болгатыгыз.20 минуттан соң тәнгә сөртегез.

## Тәмле дә.файдалы да.

Тузганак яфрагы,кузгалак,суган кыягын юып турарга. Йомырка пешереп кушарга.Үсемлек мае белән болгатырга.

## Хәкимҗан Халиков шигырьләре

**Мәтрүшкә**

Мин-мәтрүшкә,тыйнакмын

Зәңгәр чәчәк атамын

.Жанга,тәнгә ләззәт биреп,

Хуш исләр таратамын.

Дәвалыймын ютәлләрне

татлы хуш исем белән

.Авырудан арынуның

мең төрле серен беләм.

**Әрем**

Мин, гап-гади әче әрем,

Зәңгәр чәчәк атамын.

Әллә ни искитәрлек жирем

Юктыр инде.Шулай да

әйтим әле: дәвалыймын

Йокысызлык чирләрен,

Ашказанын ...

Бетерәмен хәтерсезлек чирләрен.

**Бака үләне**

Исемем сәер булса да

Мине бик хөрмәтлиләр.

Киселсә дә,канаса да

Иң әйбәт дару диләр.

**Песи үләне**

Кинәт кенә.көтмәгәндә

Авыртып китсә йөрәк.

Авыртудан дәваларга

Песи үләне кирәк.

## Йомгаклау.

Шулай итеп, кеше тормышында үсемлекләрнең роле бик зур. Организмны туклыклы матдәләрләр белән тулыландырган, витаминнарга бай булган, үзебезнең тирәлектә үскән үсемлекләрнең файдасын исбатладык. Әти-әниләргә, авылдашларга болын –кырларда үсүче ашарга яраклы үсемлекләрне бакчаларга утыртырга киңәш ителде. Халык медицинасының тормышта кулланышын белү кирәк. Ләкин табигать байлыгы чиксез түгел, дару үләннәрен дә әрәм итмичә кулланырга кирәк. Дару үләннәре кешеләрнең дә гомерләрен озынайтсыннар иде!Сакчыл караш белән алдагы көндә дә табигатьне саклыйк! Табигать белән кечкенәдән үк дуслашкан кеше – яхшы тәрбияле, мәрхәмәтле, бәхетле кеше ул! Туган төбәгенең матурлыгын күрә белүче, аны яратучы бала әти-әнисен, кардәш-ыруларын, тирә-юньдәге кешеләрне ихтирам итә. Табигать безгә сәламәтлегебез өчен күп төрле хәзинә бүләк итә. Ул хәзинәне күрә белергә, аларның кыйммәтен аңлый һәм аларны файдалана белергә генә кирә

Табигать байлыкларыннан дөрес файдаланыйк, сәламәтлегебезне саклыйк.

**Кушымта 1**

## Убыриянең сихри аланында

**(балалар иртәсе )**

**Максат.** Балаларның урман һәм андагы үсемлекләр,агачлар,куаклар,дару үләннәре,бөҗәкләр,җәнлекләр турындагы белемнәрен гомумиләштерү һәм күзаллауларын киңәйтү.Аларга карата сак караш тәрбияләү.Урманда үз-үзеңне ничек тоту кирәклеген балалардан сөйләтү.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, танып белү, физик үсеш, социаль- коммуникатив, сәнгати үсеш.

Ралина.Дусларым ,җыелыштыгызмы?

Аяз. Әйе,барыбыз да килдек.

Әминә. Кәрзиннәр алдыгызмы?Бигрәк матур кәрзиннәрегез.Әйдәгез,киттек.(әниләре рөхсәт бирүләре турында сөйләшеп алалар)

Илназ.Әнием озак тормагыз диде.

Раян. Ә миңа урманда гел бергә йөрергә куштылар.

Хәлил.Әнием кәрзиннәрегез җиләкләр белән тулсын дип теләп калды.

**Җыр: ” По малину в лес пойдём.”**

Зөлфинә. Менә җырлый-җырлый килеп тэ җиттек. Әйдәгез, кызлар, урман белән исәнләшик.

Бергә: Исәнме, урман!

Шамил. Их, урманның һавсы нинди саф. Рәхәтләнеп иркен итеп сулыйсын.

Айсылу. Тыңлагыз әле, кошлар ничек матур итеп сайрыйлар.

Самат. Ә чәчәкләрдән, җиләкләрдән хуш ис бөркелә.

Ислам. Дусларым, мин бераз ардым әле. Сусатты да. Әйдәгез әле, каен җиләге эзләп карыйк.

Гүзәл.Кызлар ,килегез әле

Менә каен җиләге.

Бик тәмле ул ,бал гына

Авызыңа ал гына.

Шифалы су эчкәндәй

Сусавыгыз басылыр,

Күңелегез ачылыр.

(ашап караганнан соң)

Рушан.Сусауны тиз баса икән бу,чыннан да.Су эзләп йөрисе юк икән урманда.

Самат.Аның яфрагы да шифалы әле.Аз гына парда тотып,ярага(җәрәхәткә) япсаң,төзәлгәнен сизми дә каласың.Әйдәгез,кызлар, сак кына яфракларын да җыйыйк.Тамыры белән йолкый күрмәгез.

Алинә.Юк,юк,без сак кына(җиләк җыялар,бер тартмага яфрагын җыялар).

Аида.Ә мин кура җиләге таптым.Килегез монда.

Кура җиләген менә

Дару дисәң дә ярый.

«Кызыл доктор » дип аңа

Исем бирсәң дә ярый.

Суык тисә вареньесын

Чәйгә салып эчәсе.

(кура җиләге җыялар )

Алина. (читкәрәк китеп) Җимешләрен күр әле син,

Сабак буйлап тезелеп төшкән.

Без киләсен көткән кебек

Барысы да изелеп пешкән.

(өзеп кабыйм дигәндз ,аның янына 1 бала йөгереп килә.)

Гүзәл. Нишлисең син,Алина?

Бу бит бүре җиләге

Аны ашап бер малай

Шундый каты чирләде,

Ярый әле үлмәде.

Кызлар, яхшылап карагыз,бүре җиләге агулы җиләк.Аны бутамагыз!

Аяз.. Кызлар,карагыз,балан да өлгергән.Бик яратам мин балан бәлешен.

Айсылу.Минем әни дә аны бик тәмле пешерә.

Әминә. Йөткерсәм дә,карлыксам

Әни миңа кич-иртә

Бераз гына бал кушып

Балан суын эчертә.

(балан җыялар,җырлыйлар)

-Әй ,балан,балан,блан

Балан баланлаганда

Баланнарга рәхәт була

Яңгыр тамгалаганда.

Баланнарны җыябыз

Какларын да коябыз

Тәмле итеп кайнатабыз,

Бәлешен яратабыз.

(җырлап бетергәч,елый-елый Куян керә.)

Куян. Ой,ой,ой!

Азалия. Нигә елыйсың,куянкай?

Куян . Чабып йөргәндә очлы чыбыкка басып ягымны канаттым.Ой,ой,ой-би-ик авырта аягым.

Алинә. Елама,Кункай,без сиңа ярдәм итәрбез.Киселсә дә,канаса да иң әйбәт дару бака яфрагы.Әйдәгез ,дусларым ,тиз генә эзләп табыйк әле шуны.

Рамазан. Менә мин таптым .(кайчы белән генә кисеп ала,юа,куянның аягын бәйли)

Куян. Рәхмәт сезгә,дусларым.(сөенеченнән җырлап җибәрә).

Бака,бакаяфрагы

Аякны дәвлады.

Юл буенда сез аны

Күрсәгез таптамагыз.

Аяк кабарса юлда

Аласың да ябасың

Шуннан шифа табасың

Торасың да чабасың.

(чыршы артында Аюның елаган тавышы ишетелә)

Илназ. Нинди тавыш анда? Кем бар икән?(Аю чыга)

Аида. Нәрсә булды камыт аяк?

Аю. Күп итеп бал ашадым,тамак кипкәч салкын су эчтем,шуннн чирләдем,тамагым бик авырта, у-у-у.

Гүзәл. Хәзер безгә кирәк инде

Мәтрүшкәнең сарысы.

Хәлил. Ул нәрсәгә ярый соң?

Раян. Бик күп төрле авыруга

Шифасы бар аның да

Тамакны да дәвалый ул

Эчәк авыруларын да.

Айгөл. Менә сиңа ,Аюкай, сары мәтрүшкә,кайнатып,тамагыңны чайкарсың.(Аю рәхмәт әйтеп китеп бара.)

Балалар игътибарларын себеркегә атланып чабучы дару үләннәренә юнәлтәләр.

Аяз. Нәрсә бу,гомеремдә беренче күрүем.Үзе оча,үзе чаба.

Инзилә. Ромашка түгелме соң бу?

Шамил. Ромашка,ромашка

Кая болай чабасың (ашыгасың) ?

Ромашка.Ашыкмый хәл юк.Соры колакка салкын тигән,шуны дәваларга барам.Убыр әбекәй очыртып җибәрде.

Балалар. Бар ,бар,тизрәк бул,соңга кала күрмә.

(Бака яфрагы битлеге кигән бала керә).

Алина. Ә син ,бака яфрагы,кая барасың?

Бака яфрагы. Тиенкәйнең күзенә арпа чыккан ,шуны дәваларга барам.

(Энҗе чәчәк керә).

Ралина. Энҗе чәчәк,энҗе чәчәк?Ә син кая чабасың?

Энҗе чәчәк.Гафу итегез,Төлкебикәнең нервылары какшаган,шуны тергезергә барам.

Раян. Кызлар,кызык бит әле бу,ә? Убыр әбекәй ниләр эшләп ята икән анда үзенең патшалыгында?

Самат. Әйдәгез,барып карыйк.(китәләр)

Убыр «Мәтрүшкәләр “не җырлап утыра.

Убыр.Менә,кунаклар килә икән.

Балалар. Исәнме ,Убыр әбекәй.

Убыр.Исәнмесез, балакайларым!Убыр түгел мин хәзер,дуктыр(доктор).

Аида. Доктор булгач,бигрәк яшәргәнсең син,әбекәй.

Убыр. И,балалар,яшәрүен яшәрмәдем инде анысы.Төрле явызлыклар эшләмим хәзер,балакайларым.

Изге эшкә керештем бит,

Барысы белән дуслаштым.

Шифаханә дә ачтым

Мунчада да чабынам

Үләннәр дә ягынам.

Әйдәгез әле,утырышыгыз,арыгансыздыр,сусагансыздыр,тамакларыгыз да ачкандыр.Мич бәрәңгесе тәгәрәткән идем учакта.Йөрәккә бик файдалы бит ул ,ашагыз әле.Аннан тузганак яфрагыннан салат ясаган идем.Салаты белән ашагыз әле,анысы да бик файдалы.

(сыйланалар). Шифалы чәйләр белән

Сыйлыйм әле ,мин сезне

Сусаганны да баса

Арганны да бетерә

Кәефләрне күтәрә

Җырлыйсы килеп китә

Биисе килеп китә.

Балалар.Чыннан да , бигрәк тә тәмле булды бу чәй,җырлыйсы да, биисе дә килеп китте.

Убыр.Әйдәгез әле , бер күңел ачып алыйк.Күптәннән биегән дә, җырлгн да юк. Бизнес белән шөгыльләнгәч,биергә вкыт калмый икән.(“Карлыган” җырын биеп җырлыйлар)Рәхмәт ,балакайларым,бигрәк булдырасыз икән.

Гүзәл. Әбекәй,киштәләрегез бик бай,сыгылып тора.

Убыр.Минем янга бик күп авырулар килә.Менә шулар өчен шифалы дару үләннәре җыеп әзерлим мин.

Айсылу. Без дә бакчада дару үләннәренең шифасы турында өйрәнәбез.

Убыр.Ягез әле,сынап карыйм үзегезне.Таныйсызмы икән,чынлап сөйлисезме икән?Менә монысы ни икән?

Раян. Бу-гөлҗимеш.Без аны салкын тимәсен дип,гел эчеп торабыз.

Убыр. Ә монысы?

Аяз. Бу –карлыган.Аның яфракларын җыеп киптердек,төнәтмә -чәйне кыш буе рәхәтләнеп эчтек.

Убыр. Я инде,син әйт.

Алинә. Монысы сары мәтрүшкә. Эч авыртканда,салкын тигәндә файдалы.

Убыр.Монысы нәрсә икән?

Хәлил.Барыбызга таныш, бу-ромашка.Аның белән тамак чайкыйбыз.

Рамазан. Монысы әрем.Күрше әбинең ашказаны авырткач,әни аңа әремне кайнатып эчертте.

Ралина.Бу- кычыткан.Аның согы,тамыры,яфраклары да бик файдалы.Аны ашка да салалар,салатын да ясыйлар.Мунчада төнәтмәсе белән коеналар,чәчне чайкыйлар.

Убыр.Мунча дигәннән,сезнең киләсен белгән күк ,мунча яктым бит әле мин,онытып торам.Кая тиз генә мунча хәстәрен күрим әле.Сез мунчада чабынырга яратасызмы соң?

Балалар. Әйе,бик яратабыз.Тик безгә әниләребез озак тормаска куштылар.

Убыр. Бер дә борчылмагыз,мин сезне үзем озатып куярмын.Әйдәгез,мунчага.Шәпме балалар,мунча.Ягез әле ятыгыз,шифалы себеркеләр белән чабыйм әле үзегезне.

-Сине каен себеркесе белән (файдасы әйтелә).

-Сине имән себеркесе белән.

-Кил әле,юкә себеркесе дә бик файдалы.Кытыгыгыз киләме әллә?Чыршы белән нарат себеркесе тиреләрне йомшарта,тирене яхшы сулата. Ягез әле,чәчләрегезне кычыткан суы белән чайкыйк,чәч төпләрегез ныгысын,кавыкламасын,чәчләрегез

ялтырап торсын,тиз үссен.Яхшылып сөртенегез дә, чыгарсыз.(балалар зур сөлгеләргә төренеп , берәм-берәм чыгалар.

Убыр.Җинел пар белән.

Балалар.Рәхмәт,әбекәй ,мунча хөрмәтенә.

Убыр.Шифалы чэйлэр эчегез дэ шушы “Шүрәле сукмагыннан” үтәрсез(массажлы юл,чикләвекләр,ташлар,күркәләр һ.б.)

**Җыр : (“Кара каш, кара күз “ көенә).**

Мунчага барган идек
Эссе пар салган идек
Пар хәлебезне алды
Тәнгә шифасы калды.

Их,мунчасы ,мунчасы,
Хуш исләр аңкып тора.
Убыр чапты ,их эссе,
Шәп икән себеркесе.

Үлән чәйләре эчтек
Ылыс ваннасы кердек
Мунча шифалы икәнен
Тагын бер тапкыр күрдек.

Убырия.Карагыз әле ,балалар,нинди тау соң бу?Балалар.Тау түгел ул,кырмыска оясы.

Убырия.Беләсез икән,балалар,сезне сынар өчен генә әйткән идем.

Балалар. Алар бик файдалы.Минем әнием күрше апа белән ел саен кырмыска оясына кул-аякларын дәваларга йөриләр.

Убырия.Әллә без дә куеп карыйбызмы? Кырмыска ояларын туздырырга ярамый,алар-урман санитарлары. Ә хәзер ял итеп алыйк. Уеннар “Исеннән таны”, “Тәменнән таны”,Кайсы азыкта нинди витамин бар”.

Убырия.Рәхмәт сезгә,балалар.Мине сөендердегез.Бик күп беләсез икән.”Нәни докторлар”икән бит сез.(күчтәнәчләр бирә,себеркесенә утыртып очыртып алып кайтып куя.)

Урманга сез дә килеп китегез

Доктор әбине  сез дә күрерсез.

Урман бик юмарт,кунак булырсыз

Саулык-байлык ул,аны саклагыз.

**Кушымта 2**

Тема. **Витаминнар.**

***(уртанчылар төркеме)***

**Проблема:** Табигый витаминнарның сәламәтлекне ныгытудагы һәм саклаудагы роле.

**Максат:** витаминлы меню төзү процессында балаларның танып белүен һәм иҗади сәләтләрен үстерү.

**Бурычлар:** Эзләнү эшчәнлеге сәләтләрен үстерү:

-куелган проблемадан чыгып бурычларны ачыклау.

-куелган бурычларга нигезләп үзеңнең эшчәнлегең этапларын ачыклау.

-салатлар әзерләү теләген үстерү.

2.Танып-белү вакытында һәм практик бурычларны хәл иткәндә балаларның баштагы белемнәрен файдаланырга өйрәтү

-куелган бурычларны хәл иткәндә күргәзмә-басма , дидактик материаллардан иркен файдалану.

3.Тупланган практик күнекмәләрне камилләштерү.

**Җиһазлау.** Күрсәтмә әсбаплар, проектор , яшелчәләр, җиләк-җимешләр, куна, пычак, алъяпкычлар, кул юу өчен савыт белән су.

**Эшчәнлек барышы:**

Тәрбияче.Балалар карагыз әле, бүген безгә кунаклар килгән. Хәзер алар белән танышып үтәрбез .

Иркәбикә.    Ашыйсым килми салат,

Яратам мин мармелад,

Кирәк түгел винегрет,

Бирегез прәнник , конфет.

Киребеткән. Бакчаларда булсын иде

Фанта, спрайт һәм пепси-кола.

Безне чирләшкә итә

Җиләк –җимеш соклары.

Т. Болар бит Киребеткән белән Иркәбикә икән. Күрегез әле үзләрен. Йөзләре агарган, үзләре хәлсез. Болар сәламәтлек турында онытып җибәргәннәр ахрысы. “Сәламәтлек үзе бер бәхет “-дигән мәкаль дә бар бит әле. Балалар, әйтегез әле, сәламәт булу өчен нишләргә кирәк?

(Гимнастика ясарга, саф һавада йөрергә, вакытында йокларга, дөрес тукланырга., витаминнар ашарга кирәк.)

Т. Ә Киребеткән белән Иркәбикәгә ничек ярдәм итәргә соң?

(Аларга витамин җитми, алар бит конфет, прәннек кенә яратабыз диләр, урамда да уйнамыйлардыр әле.)

Т. Балалар, сез нинди витаминнар бар икәнен беләсез?

(А,В, С,Д)

Киребеткән. Болар ниндидер хәрефләр саныйлар.

Иркәбикә. Алфавитны без дә беләбез аны.

Т. Балалар, сез чыннан да алфавиттагы хәрефләрне генә санадыгызмы әллә?

( Юк, без андый витаминнар булганын беләбез. Алар яшелчәләрдә, җиләк-җимешләрдә бар)

Т.Дөрес, витаминнар тагын иттә, йомыркада, сөттә, бавырда, балыкта бар. Аларда тылсымлы матдәләр бик күп. Алар Киребеткән белән Иркәбикә ише балаларга сәламәт булырга ярдәм итәләр.

Киребеткән белән Иркәбикә. Нинди тылсымлы матдәләр тагын?

Ягез әле балалар, кайсы җиләк-җимештә, яшелчәдә нинди витаминнар барлыгын, аларның файдалары турында аңлатып бирик әле.

1 бала. А витамины – кишердә, сарымсакта, помидорда, шалканда бар. Ул күз күремен яхшырта, зур үсәргә ярдәм итә. (слайд)

2 б.С витамины - карлыганда. лимонда, чиядә, помидорда, бәрәңгедә, яшел суганда бар. Ул организм өчен иң кирәкле витамин. Организмны төрле микроблардан саклый, канны чистарта. (слайд)

3 б. В витамины - кәбестәдә, кыярда бар. В витамины җитмәсә нерв системасы какшый, йөрәк эшчәнлеге бозыла. (слайд)

4 б.Д витамины - йомыркада, бавырда, кояш нурында бар. Д витамины рахит авыруыннан саклый, сөякләрне ныгыта. (слайд)

Физминут.

Рәхмәт сезгә балалар,без нинди нәтиҗә ясыйбыз инде?

1. Яшелчәләр күп төрле
Иң тәмлесе кайсысы?
Әйтсәм әйтим аларның
Бик файдалы барысы.

2.Кишер суы күп эчтем
Шуңа быел зур үстем.
Кайсын кырып ашадым,
Кайсын тешләп ашадым.
Ялкауланып тормадым
Үзем эшләп ашадым.
Сездә кишер кырыгыз,
Баллы суын эчәрсез
Күрегез дә торыгыз,
Миннән дә зур үсәрсез. (М. Туфайлова)

3. Ә мин, мәкаль беләм “Сәламәт тәндә -сәламәт акыл”.

Т. Я, Киребеткән,Иркәбикә сез без әйткән киңәшләрне аңладыгызмы инде?

Киребеткән.Исем китеп тормый әле.

Иркәбикә. Нәрсәгә кирәк безгә чөгендерләр ,кишерләр.

Т. Нишләргә инде сезнең белән? Болар яшелчәләрне яратып ашасыннар өчен нишлик икән , балалар?

(Әйдәгез төрле-төрле салатлар ясыйк.)

Т. Ә иң элек “Тәменнән таны” уенын уйнап алыйк. Уен. Тәменнән таны.

Т. Балалар витаминлы салатлар ясау өчен нәрсәләр кирәк?

( Яшелчәләр, куна,пычак, кыргыч, матур савыт-сабалар кирәк.)

Т. Кулларны юарга,алъяпкычлар бәйләргә кирәк.

(Өстәлне матур итеп бизәрбез, чәчәкләр дә куярбыз.)

Т. Иң мөһиме,куркынычсык кагыйдәләрен онытмаска кирәк.

(Бергәләп салатлар ясау)

Киребеткән.Нинди тәмле күренә.

Иркәбикә.Барысы да шундый матур, ашыйсы килә башлады.

Т. Кадерле дусларым, салатлардан авыз иткәнче,балалар сезгә аларның файдасы турында сөйләрләр.

(Салатлардан авыз итү)

**Кушымта 3.**

## Безне үлемнән алып калган үсемлекләр.

## (Тыл ветераннары белән очрашу)

Максат:Сугыш елларындакешеләрне ачлыктан,үлемнән алып калган үсемлекләр белән танышу.Кыргый үсемлекләрнең файдалы үзлекләрен ачыклау.Авыл хезмәтчәннәренең сугыш чорындагы яшәү шартларын бүгенге тормыш белән чагыштыру.

Кичә барышы:Тәрбияче.Быел җиңүнең 75еллыгын билгеләп үтәбез.

Әй ул көннәр!

Йөрәк-бәгырьләрне

Өзде инде, өзде гомергә.

Бу йөрәкләр ничек түзде икән

Калмаенча кара күмергә

Сугыш... Нишләдең соң син ? Син бит миллионнарча хатын-кызларны ирсез,

аналарны баласыз, балаларны әтисез калдырдың.. Әтиләре сугышка киткәндә

йә туып, йә туарга да өлгермәгән күпме балалар калды. Әтиләре аларның

барлыгын хат аша гына белгән, кайсылары белмичә дә һәлак булганнар. Әтиле балаларга кызыгып, үзләренең әтисез булуларына кимсенеп, әти кешене беркүрүгә, аның көчле кулын тоярга хыялланып үткән балачак...Фронттан көттерепкенә килгән, дары исе сеңгән хатларны укып юанулар...

Ралина.Җиңү көне! Халык бәйрәм итә.

Яз төренгән янар комачка.

Җир чәчәкләр тезгән күкрәгенә,

Йөз балкытып карый кояш та.

Аяз.1941 нче елда башланган Бөек Ватан сугышы 1945 нче елның 9 нчы Маенда гына тәмамлана.

Әминә.1941 ел, 22 июнь.Радио шомлы хәбәр китерә. Фашистлар Германиясе Советлар иленә вәхшиләрчә һөҗүм ясый. Ватан сугышы башлана. Шул көнне үк завод-фабрикаларда, мәктәп-институтларда, колхозларда, гомумән бөтен җирдә митинглар үткәрелә. Эшчеләр, колхозчылар, студентлар, укучылар, врачлар, барлык кеше сугышка каршы булуларын белдерәләр.

Риназ.Солдат хатыннар! Аларның тормышлары михнәтле, тамаклары ачлы-туклы, күңелләре тулы сагыну иде. Эшенә, ачлыгына түзәр идең, бала-чагаларны ятим итеп авылга туктаусыз кара печатьле кәгазьләр агылды.

Мөхәммәд. Бөек Ватан сугышы чорында зурлар белән беррәттән балалар да тиңдәшсез батырлыклар күрсәттеләр. Партизан отрядларында көрәштеләр, госпитальдә яралы сугышчыларга булыштылар, китаплар, хатлар укыдылар.

Рамазан.Халкыбыз Бөек Җиңүгә ышаныч белән яшәде һәм көрәште.

Самат.Кемгә кирәк кан-яшь кою,

Кем тели сугыш-афәт

Юкка чыксын җир йөзеннән!

Бары тынычлык булганда

Җирдә яшәве рәхәт!

Тәрбияче. Балалар ,без бүген кичәбезгә шушы авыр елларда Ватанга хезмәт куйган хөрмәтле авыл дашларыбызны чакырдык.Үзләренә сүз бирик әле.

“Сугыш башланганда мин әле кечкенә нибары дүрт яшьтә генә идем “,- дип сөйләп китте Гөлсем Миннахметова.Әтием сугышка беренче көннәреннән үк

киткән . Хушлашыр минутлар җиткәч , әти кочагына алып сөйде дә әниемә ничек итсәң ит балаларны сакла дигән. Әниемнең дурт яшлек мин,энемә ике яш.һәм декабрдә туасы энем. Бу күрешүбез соңгы тапкырдыр дип уйлап карамагандыр. Әткәй киткәннән соң бөтен эш әниемә калды.Әти киткәч кенә дөньяга килгән энебез кечкенә ,әниемә аны карарга булыштым .Алабута , башка төрле үләннәр ,черек бәрәңгедән пешерелгән ашлар төп ризык булды ..Әниләр көнне-төнгә ялгап “ Барысы да Җиңү өчен!”дип эшләделәр, оекбашлар бәйләделәр ,иген үстерделәр.

“Әй, язмыш, язмыш... Узган юллар, узган еллар, мизгелләр кинодагы кебек күз алдыннан үтә. Миңа да гомер юлымда ниләр генә күрергә туры килмәде. Сугыштан соңгы еллардагы хәлләрне үз күзем белән күреп белгәнгә, алар кабат-кабат хәтерне яңарта, йөрәкне әрнетә. Мин 1937 нче елның 20 нче августында дөньяга килгәнмен. Сугыш башланганда мин әле кечкенә, нибары дүрт яшьтә генә идем “ – дип, сөйләп китте авылдашым Әминә апа, сугыш турында хәтирәләрен барлавын үтенгәч.
Әтием сугышка китә .Әниемә нибары бер хат юллый ул. ”Исән чыгып булмас, ахры... – дип өзгәләнеп яза. Шул көннән башлап, бернинди хәбәре дә килми, хәбәрсез югала. Әнием Гөлмәдинә Сабит кызы берсеннән-берсе нәни 3 бала белән кала. Әтине сугышка озатканда хушлашыр минутлар җиткәч, әткәй мине кочагына алып яраткан. Кысып – кысып кочаклаган, - дип искә ала иде әнием. Әтәй киткәннән соң бөтен эш әнием өстендә кала. Тормышны алып барырга кирәк бит. Алабута, сәрдә,юа,какы,ат кузгалагы,башка төрле үләннәр, черек бәрәңгедән пешерелгән ашлар төп ризык булды.Юкә яфрагыннан күмәч пешерә идек. Авыр эш, сәләмә кием, ашарга җитмәү үзәккә үтте. Көн артыннан көннәр үтте. Беркөнне хат ташучының йөзен күреп, барыбыз да аптырашта калдык. Әтиебез хәбәрсез югалган дигән хәбәрне җиткерде ул безгә.Сугыш елларында күргән авырлыклар өстенә сугыштан соңгы еллар авырлыгы өстәлә. Әйе, әтисез үсүнең ачысын әле дә оныта алмый Әминә апа. Сугыш чорында балачагы туры килгән Әминә апа тырыш, булдыклы, кешелекле, авырлыклар алдында каушап калмый торган олы йөрәкле, киң күңелле, сабыр һәм шул ук вакытта гади һәм

тыйнак кеше. Шундый авыр сугыштан соңгы чорлардан соң да ул үзенең тормышта юлын тапкан.

Тәрбияче.Авыл кешесе элек-электән кыргый үсемлекләрне азык итеп кулланган. Ә сугыш елларында авыл халкын ачлыктан ,үлемнән алып коткарып калган үсемлекләр белән танышып китик.

Слайдлар карау.

Гөлҗимеш.Яш үләнчел яфракларыннан салат ясап була. Орлыкларыннан, тамырыннан чәй ясыйлар.

Кычыткан.Бу бик файдалы азык һәм дәва үсемлеге.Кычыткан яфракларын ашка,салатка турыйлар.Яз көне организмны бик күп витаминнарга һәм организм өчен кирәкле матдәләргә баета.

Ат кузгалагы.Борыңгы дару үләне.Сугыш вакытында ат кузгалагының чәчәкләрен, җитлекмәгән орлыкларын ипи пешергәндә кушканнар.

Кыргый юа.Җәй башында юа үсемлегененяфраклары сусыл вакытта ,балалар бергәләшеп болынга юага төшә торган булганнар.Ул хәзердә үзенең тәмлелеге белән дан тота.аны чәчәк атканчы кулланалар.

Балан-дару ,азык.Дарулар ясау өчен киң кулланыла.Витаминнарга бай. Балан бәлешен табын җыйганда төп ризык буларак кулланыла.

Тәрбияче. Бала һәм сугыш...Бер-берсенә туры килми торган төшенчәләр..Өлкәннәр сугышкан вакытта аларяклаучысыз калганнар.. Сугыш чоры балалары, тормышны таный башлаганчыук аның авырлыкларын үз җилкәләрендә татыганнар. Сугыш, сугыш ятим иткәнбалалар язмышы һәрвакытта да актуаль булып калачак. 75 ел гомер узды,
тагын бик күп дистә еллар үтәр, буын арты буыннар алмашыныр, ләкин Бөек
Җиңү һәм шушы Җиңүне яулап алган какшамас фронт һәм тыл
каһарманнарының якты истәлеге халык күңелендә мәңге яшәр! Безгә, яшь
буынга , Ватаныбызны яклап көрәшүче,,бүгенге көн матурлыгын бүләк итүче
әби-бабайларыбызның авыр, ачы язмышын онытырга хакыбыз юк! Һәм файдалы ,ашарга яраклы кыргый үсемлекләрне без тагын да тирәнтен өйрәнүне дәвам итәрбез.

**Кулланылган әдәбият.**

1. Дәһшәтле чор балалары. – 15 томда. Т. 7.- Казан: Тат. кит. нәшр.,2010.
2. Сугыш чоры балалар әдәбияты.- 15 томда. Т 4. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2010.
3. Җәлил М. Кечкенә дусларга: шигырьләр.-Казан: Тат. кит. нәшр.,1989.
4. Татарстан Республикасы Кызыл китабы, ред. А. А. Назиров. — Изд. 3-е. — Казань : Идел-Пресс, 2016 нчы ел
5. Миргалим Харисов төзегән “Дару үсемлекләре” китабы.
6. Ибраһимова Ф.Җ. Табигать бизәкләре. – Казан: Мәгариф, 2002.
7.Интернеттан алган мәгълуматлар